# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИАЛЬ САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ

422000, Татарстан Республикасы, Арча ш., Совет мәйданы, 14
телефон:(84366) 3-00-33,факс: 3-14-33, e-mail: 16T.009@tatar.ru


## К А Р А Р

14.03.2016 № 13

**2016 елның 13 мартында Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге территориясендә үткәрелгән җирле референдум нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 70 статьясы, «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 55,56 статьясы нигезендә, тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссияләре беркетмәләренең беренче нөсхәләре күрсәткечләре нигезендә Татарстан Республикасы Арча районы территориаль сайлау комиссиясе **2016 елның 13 мартында** узган җирле референдум нәтиҗәләре турында беркетмә төзеде:

"2016 елда Кәче авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 200 сум, көндезге бүлектә укучы студентлар, 75 яшьтән өлкәнрәк кешеләрдән 100 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар | тоту өчен акча күләме /сум |
|---|---|---|---|
| 1 | Җирлекнең җирле әһәмияттәге юлларына карата юл эшчәнлеге | - Кәче авыл Сәйдәш, Тынычлык, Тау асты урамнары юлларнын вак таш-лау; | 46100 |
| 2 | Күмү урыннарын карап тоту | - Коймалар тоту һәм зиратларны карап тору<br>- Кәче авылы<br>- Чулпан авылы | <br><br>64000<br>20000 |
| 3 | Төзекләндерүне оештыру | - ут яктырткычларын алыштыру һәм яңаларны кую | 14000 |
| 4 | Халыкны су белән тәэмин итүне оештыру | - Якты-Көн авылында коены төзекләндерү | 8000 |
| | | Барлыгы: | 152100 |

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә".

Референдум нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

референдумда катнашучылар исемлегенә тавыш бирү тәмамлануга 921 референдумда катнашучы кертелгән;

референдумда катнашучылар саны 746, бу 80,99 процент тәшкил итә;

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча референдумда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«әйе» позициясе өчен референдумда катнашкан 719 кеше тавыш бирде, бу 96,38 процент тәшкил итә;

«юк» позициясе өчен референдумда катнашкан 27 кеше тавыш бирде, бу 3,62 процент тәшкил итә.

Арча районы территориаль сайлау комиссиясе карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча районы Кәче авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны узган дип таныргa, ә референдум нәтиҗәләре гамәлдә дип таныргa.

2. Мәсьәлә буенча карар кабул итәргә:

“2016 елда Кәче авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 200 сум, көндезге бүлектә укучы студентлар, 75 яшьтән өлкәнрәк кешеләрдән 100 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар | тоту өчен акча күләме /сум |
|---|---|---|---|
| 1 | Җирлекнең җирле әһәмияттәге юлларына карата юл эшчәнлеге | - Кәче авыл Сәйдәш, Тынычлык, Тау асты урамнары юлларнын вак таш-лау; | 46100 |
| 2 | Күмү урыннарын карап тоту | - Коймалар тоту һәм зиратларны карап тору<br>- Кәче авылы<br>- Чулпан авылы | <br><br>64000<br>20000 |
| 3 | Төзекләндерүне оештыру | - ут яктырткычларын алыштыру һәм яңаларны кую | 14000 |
| 4 | Халыкны су белән тәэмин итүне оештыру | - Якты-Көн авылында коены төзекләндерү | 8000 |
| | | Барлыгы: | 152100 |

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә".

3. Җирле референдумның гомуми нәтиҗәләрен Арча муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru).

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе рәисе Б.И. Кадыйров

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе секретаре Л.И. Нурмиева